ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

# «Оешмалар мөлкәтенә салым турында» Татарстан Республикасы Законының 3 статьясына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2022 елның 21 апрелендә
кабул ителде

**1 статья**

«Оешмалар мөлкәтенә салым турында» 2003 елның 28 ноябрендәге 49-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 3 статьясына (2010 елның 5 июлендәге 51-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы редакциясендә) (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2003, № 11; 2010, № 7 (II өлеш); 2011, № 5, № 8 (I өлеш); 2012, № 2, № 6 (I өлеш); 2013, № 3, № 6 (II өлеш), № 10, № 12 (I өлеш); 2014, № 10 (I өлеш); 2015, № 6 (I өлеш), № 8 – 9; 2016, № 1 – 2, № 6 (III өлеш); Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2016, № 44 (I өлеш); 2017, № 1 (I өлеш), № 17 (I өлеш), № 50 (I өлеш), № 94 (I өлеш); 2018, № 1 (I өлеш), № 54 (I өлеш); 2019, № 49 (I өлеш); 2020, № 26 (I өлеш), № 57 (I өлеш); 2021, № 1 (I өлеш), № 36 (I өлеш), № 49 (I өлеш), № 77 (I өлеш), № 93 (I өлеш); 2022, № 3 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) $1^1$ өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«$1^1$. Оешмалар салымның исәпләнгән суммасыннан 0,46 процент күләмендәге салымны 2011 елның 1 гыйнварыннан 2014 елның 1 гыйнварына кадәр эксплуатациягә кертелгән, техник документация буенча машина урыннары саны кимендә 100 берәмлек булган автомототранспорт чараларын куеп торуның күпкатлы һәм җир асты урыннарында (парковкаларында) автомототранспорт чараларын куеп тору урыннары (парковкалар) хезмәтләре күрсәтү өчен билгеләнгән мөлкәткә карата, автомототранспорт чараларын куеп тору урыннары (парковкалар) хезмәтләре күрсәтү өчен әлеге куеп тору урыннарының (парковкаларның) гомуми мәйданының кимендә 70 процентын файдалану шарты үтәлсә, түли.»;

2) 2 өлештә:

а) беренче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Салымның исәпләнгән суммасыннан 4,55 процент күләмендәге салым түбәндәге рәвештә түләнә:»;

б) 1 пунктта:

беренче абзацта «сатып алынган мөлкәткә» сүзләрен «сатып алынган мөлкәткә карата» сүзләренә алмаштырырга;

икенче абзацта «ставкасын» сүзен «ташламасын» сүзенә алмаштырырга;

алтынчы абзацта «ставкасын» сүзен «ташламасын» сүзенә алмаштырырга;

җиденче абзацта «ставкасын» сүзен «ташламасын» сүзенә алмаштырырга;

сигезенче абзацта «ставкасын» сүзен «ташламасын» сүзенә алмаштырырга;

в) 8 пунктта «оешмалар» сүзен «оешмалар тарафыннан» сүзләренә алмаштырырга;

г) 14 пунктта «оешмалар» сүзен «оешмалар тарафыннан» сүзләренә алмаштырырга;

д) 15 пунктта «оешмалар» сүзен «оешмалар тарафыннан» сүзләренә алмаштырырга;

3) $2^1$ өлештә:

а) беренче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«$2^1$. Салымның исәпләнгән суммасыннан 22,73 процент күләмендәге салым түбәндәге рәвештә түләнә:»;

б) 1 пунктта «җитештерүчеләрнең» сүзен «җитештерүчеләр тарафыннан» сүзләренә алмаштырырга;

в) 2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2) инновацияле проектларны гамәлгә ашыру өчен Россия Федерациясе яисә Татарстан Республикасы хөкүмәтләре карарлары нигезендә булдырылган технопарклар (индустриаль парклар), инновацияле-технологик үзәкләр тарафыннан – түләп вакытлыча хуҗа булуга һәм файдалануга яисә вакытлыча файдалануга бирү өчен билгеләнгән мөлкәткә карата;»;

г) 3 пунктта «оешмалар» сүзен «оешмалар тарафыннан» сүзләренә алмаштырырга;

д) 4 пунктта «оешмалар» сүзен «оешмалар тарафыннан» сүзләренә алмаштырырга;

е) 5 пунктта «оешмалар» сүзен «оешмалар тарафыннан» сүзләренә алмаштырырга.

**2 статья**

Әлеге Закон 2023 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты — Р.Н. Миңнеханов

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ АППАРАТЫ · АППАРАТ ПРЕЗИДЕНТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ

Казан, Кремль
2022 ел, 27 апрель
№ 21-ТРЗ